
Хәерле көн, дуслар!
Уңышлар телим сезгә!

*«Тел дигән дәрья бар,*
*Төбендә энҗе-мәрҗән бар.*
*Белгәннәр чумып алыр,*
*Белмәгәннәр коры калыр”.*

# Җылы төс белән генә язылган хәрефләрне җыйнасагыз, дәрес темасы килеп чыгар.

*А К И Л У З Ң Ш Ө Ч*

*Ы Р М П Х Ч Е А*

*Ф Л Й Ү А Т Р*

# Күрмә диктант

- Эшнең ояты юк.
- Эшсез кеше – акмас су.
- Эшчән кеше-имәндәй,

Ялкау кеше яфрактай.

**Бирелгән сүзләр арасыннан ясагыч кушымчалы сүзләрне генә язып алыгыз.**

Белем, биеклек, умарта, ташкүмер, дус, урын-җир, умартачылык, ташбака, җырчы, көн-төн, яшелчә.

# Текстта төшеп калган кушымчаларны куеп укыгыз.



Канатлы дусларыбыз.

Кошлар урман... этажлап яшиләр. Урман... һәр катлавының үз кошлары бар. Алар анда яшел дусларыбыз... корткычлар... саклый-лар. Зур чуар тукран... гына алыйк. Ул чын-чыннан урман сакчысы. Үзе... өтерге кебек үткен томшыгы белән агач кәүсәләр... тикшерә.

# Тикшерү үрнәге

Моңсулык – ясалма сүз.

Моң – тамыры.

-су, -лык – сүз ясагыч кушымчалары ялганган.

## Бирелгән сүзләрне өч баганага аерып языгыз.

# Дәресләр, дәреслек, дәрестә; ауда, аучы, аулый; эшли, эштә, эшче, эшкә; дуслык, дустанә, дусның.

## Бирелгән сүзләрне сүз төзелеше буенча тикшерегез:

Хайваннар, кошчылык, көнгә, җырчылар, ач-кыч.


Афәрин, кадерле укучылар!
Һәрвакыт шулай тырыш
булыгыз!